**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2022 елның 29 апреле** **1126 номер**

# КАРАР

**Кадастр номерлары 16:24:010402:894, 16:24:010402:895, 16:24:010402:893, 16:24:010402:892, 16:24:000000:6823, 16:24:000000:6822 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында**

Планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, гомуми файдалану территорияләре чикләрен, планлаштырылган капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү, территориянең планлаштырылган үсеш характеристикаларын һәм чиратлылыгын билгеләү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 43, 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, **карар бирәм**:

1. Кадастр номерлары 16:24:010402:894, 16:24:010402:895, 16:24:010402:893, 16:24:010402:892, 16:24:000000:6823, 16:24:000000:6822 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләре нигезендә билгеләргә.

3. Ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2023 ел ахырына кадәр билгеләргә.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга проектны әзерләү тәртибе, сроклары, шулай ук проектның эчтәлеге турында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдимнәр җибәрергә..

5. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге генераль планында булган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүмат белән бәйле рәвештә, проектны раслаганчы, кызыксынган затка археологик эзләнүләр уздырырга һәм мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты белән эзләнү мәгълүматларын килештерергә кирәк..

6. Әлеге проектны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә йөкләргә.

7.Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**